РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-42-05, факс: (85593) 2-80-13

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _________ 202 г. №_____

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы территориясендә
рекреация зоналарын раслау турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Су кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, "Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты к а р а р  и т т е:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә кушымтада бирелә торган рекреация зоналары реестрын расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru; 17.12.2013 елны Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан ЭЛ № ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык бирелгән) бастырып чыгару һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесе С.П. Самонина

В.А.Андреева
8(85593)2-42-07

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына кушымта
«___»_________2025 ел №_____

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендәге рекреация зоналар реестры

| № т/б | Ял итү зонасы исеме | Төре | Адресы | Географик координаталар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Әбсәләм авылының Иске Карьер күле | пляж | Әбсәләм авыл җирлеге | 54.572819, 53.445246 |